Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № I-4**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 22 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт проектын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 48 статьясы нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2015 елның
22 сентябрендәге I-4 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт проекты**

«__» ________, 2015 ел                                        Балык Бистәсе штп.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25 - ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы (алга таба-Устав) нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы (алга таба – Башлык) бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе _____________________________________________ (алга таба - Башкарма комитеты җитәкчесе), икенче яктан, түбәндәгеләр турында әлеге контрактны төзеделәр.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге контракт Башкарма комитет җитәкчесе һәм җирле үзидарә органнары арасында хезмәт һәм башка мөнәсәбәтләрне җайга сала, закон һәм устав нигезендә әлеге контракт якларының хокукларын һәм бурычларын билгели.

1.2. Башкарма комитет җитәкчесе законнар, устав һәм әлеге контракт белән билгеләнгән шартларда әлеге контракт гамәлдә булган чорда Башкарма комитетка җитәкчелек итү буенча вазыйфаларны үз өстенә ала.

2. Контрактның төп шартлары

2.1. Башкарма комитет җитәкчесе конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан вазыйфага билгеләнә.

2.2. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль хезмәткәр булып тора һәм Башкарма комитетны җитәкли.

2.3. Башкарма комитет җитәкчесе үз эшчәнлегендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык контролендә һәм аларга хисап тота.

2.4. Әлеге контракт буенча эш Башкарма комитет җитәкчесе өчен төп эше булып тора.

2.5.Башка шартлар ___________________________________________

_______________________________________________________________

3. Башкарма җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары
җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә

3.1. Башкарма комитет җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары законнар, устав, башка муниципаль хокукый актлар һәм әлеге контракт белән билгеләнә.

3.2. Башкарма комитет җитәкчесе:

3.2.1. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлеге белән бер үзе принцибында җитәкчелек итә (алга таба-Башкарма комитет) һәм үз компетенциясенә кергән вәкаләтләрен үтәве өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык алдында шәхси җаваплылык тота;

3.2.2. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, Башлык, башка җирле үзидарә органнары, шул исәптән башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Башкарма комитетны тәкъдим итә;

3.2.3. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каравына муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнары һәм программалары проектларын һәм аларның үтәлеше турында хисаплар тәкъдим итә;

3.2.4 муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органын раслауга Башкарма комитет структурасы проектын, Башкарма комитет хезмәткәрләренең иң чик санын һәм аларның хезмәтенә түләү фондын кертә, Башкарма комитетның штат расписаниесен хезмәткәрләрнең иң чик саны һәм хезмәткә түләү фонды белән расланган структура нигезендә раслый;

3.2.5. Башлык белән килешеп билгели һәм Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитет органнары җитәкчеләрен вазыйфадан азат итә, үз урынбасарлары арасында вазыйфаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

3.2.6. расланган бюджет нигезендә муниципаль берәмлек акчалары белән эш итә, законнар нигезендә муниципаль берәмлекнең бюджет һәм башка счетларын ача һәм яба;

3.2.7. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына Башкарма комитет эшчәнлеге һәм үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисаплар тапшыра, шул исәптән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында;

3.2.8. Башкарма комитет эшчәнлеге турында халыкка даими рәвештә мәгълүмат бирә, Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга кимендә бер тапкыр гражданнарны кабул итә, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

3.2.9. дәүләт һәм башка органнарда муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар күрә, Башкарма комитет исеменнән судка гаризалар, ышаныч кәгазьләре бирә;

3.2.10. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы законнары, уставы, карарлары һәм әлеге контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.3. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль берәмлек исеменнән мөлкәт һәм башка хокукларны һәм бурычларны сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәсез чыгыш ясарга хокуклы.

3.4. Башкарма комитет җитәкчесе федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының уставы, норматив хокукый актлары белән билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә Башкарма комитетның җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен, шулай ук Башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча башкарма комитет боерыкларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарларын чыгара.

3.5.Башка хокуклар_____________________________________________
______________________________________________________________.

3.6. Башкарма комитет җитәкчесе бурычлы:

3.6.1. Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, Уставны һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык карарларын үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

3.6.2. гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне һәм яклауны тәэмин итәргә;

3.6.3. законнарда, устав, башка муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә Башлык, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, башка җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;

3.6.4. үз вазыйфаларын намус белән башкарырга;

3.6.5. хезмәт бурычларын үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

3.6.6. дәүләт һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне, шулай ук үз вәкаләтләренең үтәлеше белән бәйле аңа билгеле булган мәгълүматларны таратмаска, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагылышлы мәгълүматларны;

3.6.7. законнар нигезендә муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә;

3.6.8. Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә үзе һәм гаилә әгъзалары турында мәгълүматларны тапшырырга;

3.6.9. дәүләт һәм муниципаль милекне, шул исәптән вәкаләтләрне үтәү өчен бирелгән мөлкәтне сакларга.

3.7. Үз вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу очракларын булдырмаска тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликты дигәннән Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынуы аның вазыйфа йөкләмәләренең объектив үтәлешенә йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин булган һәм Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынуы белән гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең законлы мәнфәгатьләре арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла, ул гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең бу законлы мәнфәгатьләренә зыян китерергә мөмкин.

Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынуы дигәннән Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан керемнәрне (нигезсез баю) акчалата яки натураль рәвештә башкарганда, турыдан-туры Башкарма комитет җитәкчесе өчен матди файда рәвешендәге керемнәрне матди яктан алу мөмкинлеге аңлашыла, аның гаилә әгъзалары һәм туганнары (эти-әниләре, ирләре, балалары, энеләре, сеңелләре, апалары, аларның эти-әниләре, балалары һәм аларның балалары), шулай ук Башкарма комитет җитәкчесе финанс яисә башка йөкләмәләр белән бәйле гражданнар яки оешмалар өчен.

Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынуы туган очракта, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала икән, Башкарма комитет җитәкчесе бу турыда Башлыкка язма рәвештә хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны (низаг, каршылыкны) булдырмау буенча чаралар күрергә тиеш.

3.8. Башкарма комитет җитәкчесе законнар, устав, башка муниципаль хокукый актлар, әлеге контракт белән билгеләнгән башка бурычларны үтәргә тиеш.

3.9. Башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен башкарганда муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрендә эш итәргә, үз хокукларын гамәлгә ашырырга һәм вазыйфаларын намуслы һәм акыллы башкарырга тиеш.

3.10.Бүтән бурыч-йөкләмәләр ____________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________.

4. Башкарма комитет җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары
җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә

4.1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет җитәкчесе хокуклы:

4.1.1. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән нигезләмәләрне гамәлгә ашырырга һәм бастырып чыгарырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар, шулай ук Башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр, аның үтәлеше аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәк;

4.1.2. федераль башкарма хакимият органнарыннан, аларның территориаль органнарыннан федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

4.1.3. җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан соратып алырга;

4.1.4. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе, шулай ук аларны кирәкле матди ресурслар һәм финанс чаралары белән тәэмин итү турында тәкъдим белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгать итәргә;

4.1.5. вәкиллекле органга устав белән каралган очракларда һәм тәртиптә бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану турында тәкъдимнәр кертергә;

4.1.6. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча закон таләпләрен бозуларны бетерү турында дәүләт органнарының күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять бирергә;

4.1.7. аерым дәүләт вәкаләтләрен бирүне күздә тоткан федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән хокукларны кулланырга.

4.2. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет җитәкчесе бурычлы:

4.2.1. аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Башкарма комитет эшен оештырырга;

4.2.2. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди ресурсларны һәм финанс чараларын саклауны һәм максатчан куллануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре чикләрендә кабул итәргә, шулай ук устав белән каралган очракларда һәм тәртиптә бу

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан өстәмә кулланыла торган үз матди ресурслары һәм финанс чаралары;

4.2.3. Россия Федерациясе вәкаләтле дәүләт органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы вәкаләтле дәүләт органнарына федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нигезләмәләр нигезендә чыгарылган муниципаль хокукый актлар турында мәгълүматларны тапшырырга, алар белән җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган;

4.2.4. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга;

4.2.5. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы вәкаләтле дәүләт органнарына әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга;

4.2.6. федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торганда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына ярдәм итәргә;

4.2.7. җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм итәргә;

4.2.8. үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнарының яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе дәүләт органнары вәкаләтле вәкилләренең язмача күрсәтмәләрендә күрсәтелгән Федераль закон таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә;

4.2.9. җирле үзидарә органнарының яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары вәкаләтле вәкилләренең язмача күрсәтмәләрендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы законнары таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар кабул итәргә;

4.2.10. вәкаләтле дәүләт органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләп ителә торган финанс чыгымнарын исәпләүне тапшырырга;

4.2.11. җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокларда матди ресурсларны һәм кулланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

4.2.12. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре тапшырылган федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы

законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм шартлар килеп ирешкәндә аларны гамәлгә ашыруны туктатуга юнәлдерелгән чараларны күрергә.

## 5. Башлыкның хокуклары һәм бурычлары

5.1. Башлык хокуклы:

5.1.1. Башкарма комитет җитәкчесеннән үз вазыйфаларын башкарганда Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставын, карарларын һәм муниципаль берәмлек Башлыгы карарларының үтәлүен таләп итәргә;

5.1.2. Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә мәҗбүри үтәлергә тиешле йөкләмәләр бирергә (йомышлар кушарга);

5.1.3. Башкарма комитет җитәкчесеннән муниципаль берәмлек башлыгының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле бәяләмәләрне, документларны, белешмә һәм башка мәгълүматны соратып алырга, шул исәптән соратып алына торган яисә башка килешенгән срокларда тапшырылырга тиешле Башкарма комитет эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә;

5.1.4. Башкарма комитет җитәкчесенә законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә кызыксындыру чаралары кулланырга;

5.1.5. закон нигезендә хезмәт вазыйфаларын үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен Башкарма комитет җитәкчесен дисциплинар җаваплылыкка тартырга;

5.1.6. Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы әлеге контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә әлеге контрактны вакытыннан алда туктату турында судка мөрәҗәгать итәргә;

5.1.7.бүтән хокуклар ________________________________________________
_____________________________________________________________________.

5.2. Башлык башкарма комитет җитәкчесенең законнарда, муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта каралган хокукларын һәм гарантияләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча чаралар күрә.

5.3. Башлык Башкарма комитет җитәкчесен медицина бәяләмәсе нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәү өчен күрсәтмәләрне ачыклаганда биләгән вазыйфаларыннан (вазыйфа йөкләмәләрен башкаруга юл куймаска) туктатырга тиеш, федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән вәкаләтле органнар һәм вазыйфаи затлар таләпләре буенча һәм законнарда каралган башка очракларда.

5.4. Район Башлыгының башкарма комитет җитәкчесе һәм Башкарма комитет органнары белән үзара эшчәнлек (хезмәттәшлек) буенча башка

вәкаләтләре законнар, устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

## 6. Башкарма комитет җитәкчесенең хезмәт хакы һәм эш вакыты режимы

6.1. Башкарма комитет җитәкчесенә гамәлдәге законнар һәм муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары нигезендә акчалата хезмәт хакы түләнә.

6.2. Башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфаи айлык хезмәт хакы күләме, инфляция (кулланучылар бәяләре) дәрәҗәсен исәпкә алып, ел саен муниципаль берәмлек бюджеты нигезендә арта (индексацияләнә). Хезмәт хакын арттыру (индексацияләү) турында карар район Башлыгы тарафыннан кабул ителә.

6.3. Башкарма комитет җитәкчесе үз эшчәнлеген нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында башкара.

## 7. Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруының социаль-көнкүреш һәм башка шартлары

7.1. Хезмәт бурычларын үтәү өчен Башкарма комитет җитәкчесенә тәүлек әйләнәсе эш графигы һәм мобиль элемтә чаралары белән идарә итүчесе белән хезмәт урыны автомашинасы бирелә.

7.2. Башкарма комитет җитәкчесенә командировка чыгымнары каплана, башка түләүләр башкарыла, шулай ук еллык түләүле отпуск һәм муниципаль берәмлек вәкиллекле органының законнар һәм норматив хокукый актлары белән муниципаль хезмәткәрләр, Башлык тарафыннан билгеләнгән башка гарантияләр бирелә.

7.3.Бүтән шартлар ________________________________________________
_____________________________________________________________________.

## 8. Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләр вакыты

8.1. Башкарма комитет җитәкчесе әлеге контракт төзелгән көннән үз вәкаләтләрен тормышка ашыра башлый.

Әлеге контракт муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре срогына төзелә, ул затны Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләп кую турында Карар кабул итә (яңа чакырылыш муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы эшли башлаган көнгә кадәр), һәм тәшкил итә ______________.

8.2. Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

8.2.1. үлем;

8.2.2. үз теләге белән отставкага китү;

8.2.3. законда билгеләнгән тәртиптә әлеге контрактның өзелүе;

8.2.4. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан азат итү;

8.2.5. суд тарафыннан хокукый сәләтсез яки чикләнгән сәләтле дип тану;

8.2.6. суд тарафыннан билгеле булмаган (юк булу) дип танылу яки үлгән дип игълан ителү;

8.2.7. аңа карата судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

8.2.8. Россия Федерациясеннән даими яшәү урынына чыгу;

8.2.9. Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга, аларга чит дәүләтнең гражданлыгын алырга, яисә аларга яшәргә рөхсәт яисә Чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданының даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алырга хокуклы, халыкара шартнамәдә катнашучы түгел, аның нигезендә Россия Федерациясе гражданы, чит ил гражданлыгы булган җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;

8.2.10. хәрби хезмәткә чакыру яки аны алыштыручы альтернатив гражданлык хезмәтенә юллама;

8.2.11. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13 статьясындагы 4, 6 өлешләре нигезендә, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта башкарыла торган муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору;

8.2.12. җирлекнең муниципаль берәмлек статусын шәһәр округы белән берләшү сәбәпле югалтуы;

8.2.13. муниципаль берәмлек сайлаучылары санының 25 проценттан артып китүе, муниципаль берәмлек чикләре үзгәрү яки җирлекнең шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә килеп чыккан;

8.2.14. Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләрен башкаручының Башлык вазыйфасына керешүе.

8.3. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының вәкаләтләре срогы узгач яки аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату буенча башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны билгеләнгән тәртиптә башкарма комитетның яңа җитәкчесен билгеләгәнгә һәм аның белән контракт төзегәнгә кадәр дәвам итә.

## 9. Якларның җаваплылыгы

9.1. Әлеге контрактны үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен яклар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

9.2. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль берәмлеккә, башкарма комитетка аның гаебе белән китерелгән зыян өчен тулы матди җаваплылык йөртә. Әлеге җаваплылык тиешле суд карары нигезендә йөкләнә.

9.3. Башкарма комитет җитәкчесе федераль законнар нигезендә җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы

законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкармаган яисә тиешенчә гамәлгә ашырмаган өчен шушы максатларга бүлеп бирелгән муниципаль берәмлеккә матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җаваплы була.

9.4. Башлык билгән вазыйфасыннан (вазыйфаи бурычларын үтәүгә юл куймаска) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу чорында башкарма комитет җитәкчесен читләштерергә хокуклы. Шул ук вакытта Башкарма комитет җитәкчесенә билгән вазыйфасыннан читләштерүнең барлык вакытына акчалата түләү саклана.

9.5.Бүтән шартлар ___________________________________________
________________________________________________________________.

## 10. Контрактны үзгәртү һәм өзү. Бәхәсләрне хәл итү

10.1. Һәр як та, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланганнан соң, контрактка кушымта итеп бирелә торган өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә торган әлеге контрактны үзгәртү (төгәлләштерү) яисә өстәү турындагы мәсьәләне икенче як алдына куярга хокуклы.

10.2. Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт яклар килешүе буенча вакытыннан алда яисә суд тәртибендә гариза нигезендә өзелергә мөмкин:

10.2.1. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы яисә Башлык - җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда контракт шартлары бозылуга бәйле рәвештә;

10.2.2. Татарстан Республикасы Президенты - контракт шартларын федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда бозуга бәйле рәвештә;

10.2.3. Башкарма комитет җитәкчесе - җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары контракты шартлары бозылуга бәйле рәвештә.

10.3. Якларның ризалыгын күздә тоткан очракларда контрактны вакытыннан алда өзү турындагы тәкъдим башка якка контрактны туктатуның күздә тотыла торган срогына кадәр ике айдан да соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.

10.4. Яклар арасындагы бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## 11. Контрактның гамәлдә булу вакыты

11.1. Әлеге контракт әлеге контрактның 8.1 пункты нигезендә Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң башкарма комитетның яңа җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә билгеләнгәнче һәм аның белән контракт төзелгәнче гамәлдә була. Яңа җитәкче белән контракт төзелгән көннән әлеге контрактның гамәлдә булуы туктатыла һәм башкарма комитет җитәкчелеге буенча вәкаләтләр Башкарма комитетның яңа җитәкчесенә күчә.

11.2. Башкарма комитет җитәкчесе белән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә контракт аның вәкаләтләре чоры дәвамында гамәлдә була, әмма, әгәр әлеге вәкаләтләр билгеле бер срокка ия булса, аерым дәүләт вәкаләтләренең гамәлдә булу срогы дәвамында гамәлдә була.

11.3. Әлеге контрактның гамәлдә булуы башкарма комитет җитәкчесенең законнар һәм әлеге контрактның 8.2 пункты нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән (әлеге контрактның 11.1 пункты белән билгеләнгән сроктан алда) туктатыла.

## 12. Йомгаклау нигезләмәләре

12.1. Әлеге контракт яклар имзалаган көннән үз көченә керә.

12.2. Вәкаләтләр срогы узганнан яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң, Башкарма комитет җитәкчесе барлык мөһерләрне, штамплар, финанс һәм аның эшендәге башка документларны, сейфларның ачкычларын яңа билгеләнгән Башкарма комитет җитәкчесенә яисә аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затка кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырырга тиеш.

12.3. Әлеге контракт бер үк төрле юридик көчкә ия өч нөсхәдә төзелгән, алар түбәндәгечә саклана: бер нөсхә - Башкарма комитетның кадрлар хезмәтендә (Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси эшендә), бер нөсхәсе-Башлыкта, бер нөсхә - Башкарма комитет җитәкчесендә.

### Якларның имзалары һәм реквизитлары:

| | |
|---|---|
| Башлык _________________________ | Башкарма комитет җитәкчесе___________________ |
| | Паспорт мәгълүматлары: _________________________ ______________________________________________ |
| | Адрес: ______________________________________ |
| _______________________________ | ______________________________________________ |
| (имза ) (Ф.И.А.и.) | (имза) (Ф.И.А. и.) |